РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.05.2026 Кукмара ш. № 277

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы муниципаль оешмасы тарафыннан аренда шартнамәсе, үзенә беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары кыйммәтләрен раслау хакында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яисә муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыруның гомуми принциплары хакында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы дәүләт яисә муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган дәүләт яки муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыруның, әлеге бәяләүләрнең критерийларын да кертеп, гомуми принциплары хакында, шулай ук мондый карарлар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзүнең һәм аның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 24 июлендәге 1194 номерлы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Расларга:

1.1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы муниципаль оешмасы тарафыннан аренда шартнамәсе, үзенә беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары кыйммәтләре;

1.2. 2 нче кушымта нигезендә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары кыйммәтләре;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 04.05.2026 елның 277 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы муниципаль оешмасы тарафыннан аренда шартнамәсе, үзенә беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары кыйммәтләре

| т/б № | Критерий | Кыйммәте |
|---|---|---|
| 1. | Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль милке булган реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, билгеләнешен үзгәртүгә яисә бетерүгә, шулай ук аны арендага, түләүсез файдалануга тапшыруга тәкъдим ителә торган балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан (алга таба - социаль инфраструктура объекты) файдаланып балаларга социаль хезмәт күрсәтүне дәвам итүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән/ Тәэмин ителмәгән |
| 2. | Балаларның тормыш эшчәнлеген, белем алуын, үсешен, ялын һәм сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә, билгеләнешен үзгәртүгә яисә бетерүгә, шулай ук арендага, түләүсез файдалануга тапшыруга тәкъдим ителә торган социаль инфраструктура объектыннан файдаланып күрсәтелә торган мондый хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзи торган федераль дәүләт оешмасы тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул ителгәнче балаларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән/ Тәэмин ителмәгән |

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 04.05.2026 елның 277 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары кыйммәтләре

| т/б № | Критерий | Кыйммәте |
|---|---|---|
| 1. | Үзгәртеп оештыру яки бетерүгә тәкъдим ителә торган балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерүче федераль дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган, балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында балаларга социаль хезмәт күрсәтүне дәвам итүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән/ Тәэмин ителмәгән |
| 2. | Үзгәртеп оештыру яки бетерүгә тәкъдим ителә торган балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерүче федераль дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган, балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтүнең федераль дәүләт оешмасы күрсәтә торган мондый хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә социаль хезмәт күрсәтү максатларында, әлеге оешманы үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында карар кабул ителгәнче, балаларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән/ Тәэмин ителмәгән |
| 3. | Реорганизацияләүгә яисә бетерүгә тәкъдим ителә торган балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерүче федераль дәүләт оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны дәвам итүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән/ Тәэмин ителмәгән |